**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 26 май № 307

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль учреждениеләре хезмәткәрләрен шифаханә-курорт дәвалавы белән тәэмин итү тәртибен раслау турында» 2004 ел, 16 апрель, 184 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2004 ел, 30 декабрь, 586 нчы; 2006 ел, 6 февраль, 43 нче; 2006 ел, 3 апрель, 146 нчы; 2006 ел, 1 декабрь, 585 нче; 2007 ел, 7 ноябрь, 607 нче; 2007 ел, 26 декабрь, 744 нче; 2009 ел, 14 гыйнвар, 10/1 нче; 2009 ел, 30 гыйнвар, 45 нче; 2010 ел, 6 декабрь, 1002 нче; 2014 ел, 8 июль, 472 нче; 2015 ел, 19 март, 165 нче; 2015 ел, 25 ноябрь, 890 нчы; 2016 ел, 9 август, 549 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль учреждениеләре хезмәткәрләрен шифаханә-курорт дәвалавы белән тәэмин итү тәртибендә (алга таба – Тәртип):

1.2 нче пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.2. Ташламалы шартларда юлламалар белән гаиләләренең җан башына уртача кереме Татарстан Республикасы буенча халыкның җан башына яшәү минимумының 500 процентыннан артмаган Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль мәгариф оешмалары, Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль медицина оешмалары, Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль мәдәният оешмалары, Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль социаль яклау, социаль хезмәт күрсәтү, эш белән тәэмин итү оешмалары, Татарстан Республикасының яшьләр эшләре һәм спорт буенча дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләре (алга таба – хезмәткәрләр) Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау һәм социаль үсеш министрлыгының «Авыруларны медицина күрсәткечләре нигезендә сайлап алу һәм шифаханә-курорт дәвалавына җибәрү тәртибе турында» 2004 ел, 22 ноябрь, 256 нчы боерыгы белән билгеләнгән тәртиптә

һәм Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының «Амбулатор шартларда медицина ярдәме күрсәтүче медицина оешмаларында кулланыла торган медицина документларының унификацияләнгән формаларын һәм аларны тутыру тәртипләрен раслау турында» 2014 ел, 15 декабрь, 834н номерлы боерыгы белән расланган 070/у формасы буенча бирелгән белешмә кәгазе (алга таба – 070/у формасы буенча юллама алу өчен белешмә кәгазе) белән расланган медицина күрсәткечләре булган шартларда (Россия Федерациясе норматив хокукый актлары нигезендә шифаханә-курорт дәвалавына хокукы булган халык категорияләренә кергән гражданнардан тыш) тәэмин ителә.»;

1.7 нче пунктта «18 календарь көне» сүзләрен «14 календарь көне» сүзләренә алмаштырырга;

2.1 нче пунктның икенче абзацында «070/у-04 формасы буенча» сүзләрен «070/у формасы буенча» сүзләренә алмаштырырга, «(бирелгән көннән 6 ай эчендә гамәлдә була)» сүзләрен төшереп калдырырга;

3.3 нче пунктның икенче абзацында «070/у-04 формасы буенча» сүзләрен «070/у формасы буенча» сүзләренә алмаштырырга;

3.6 нчы пунктның икенче абзацында «070/у-04 формасы буенча» сүзләрен «070/у формасы буенча» сүзләренә алмаштырырга;

Тәртипкә 2 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (карарга теркәлә).

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы пенсионерларын шифаханә-курорт дәвалавы белән тәэмин итү тәртибен раслау турында» 2011 ел, 14 февраль, 97 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 11 февраль, 105 нче; 2014 ел, 2 сентябрь, 635 нче; 2015 ел, 19 март, 165 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешне кертергә:

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы пенсионерларын шифаханә-курорт дәвалавы белән тәэмин итү тәртибенең 1.5 нче пунктында «18 көн» сүзләрен «14 календарь көне» сүзләренә алмаштырырга.

3. Бу карарның 1 нче пунктындагы бишенче абзац һәм 2 нче пунктындагы икенче абзац 2018 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

F:\KARAR\2017\307.doc

Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль учреждениеләре хезмәткәрләрен шифаханә-курорт дәвалавы белән тәэмин итү тәртибенә 2 нче кушымта
Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2017 ел, 26 май, 307 нче карары редакциясендә)

Форма

_____________________________________________
(Татарстан Республикасы муниципаль районындагы (шәһәр округындагы) беренчел һөнәр берлеге оешмасына яки территориаль социаль яклау органына)
______________________________ хезмәткәре
(учреждение исеме)
_____________________________________________
_____________________________________________,
(фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда))
паспорт сериясе _________ № _____________
____________________________________________,
____________________________________________
___________________ адресы буенча яшәүче,
телефон ________________________________,
e-mail: ___________________________________

ГАРИЗА.

Миңа 070/у формасы буенча юллама алу өчен белешмә кәгазе нигезендә 20___ елның ___________ ______________________шифаханәсенә юллама бирүегезне үтенәм.
(ай) (исеме)

Юлламаны соңгы тапкыр алган дата: 20___ елның ______________________.
(ай)

Шифаханә-курорт дәвалавына юлламалар белән тәэмин итү тәртибе шартлары белән таныштым.

Гаризага түбәндәгеләрне терким:

1. 070/у формасы буенча юллама алу өчен белешмә кәгазе.
2. Гариза биргән ай алдыннан килгән соңгы өч ай өчен гаиләнең һәр әгъзасы керемнәрен раслый торган документлар, ______ б., _______ нөсхәдә.
3. ___________________________ (теләк буенча башка документлар).

Тапшырылган мәгълүматларның һәм документларның дөреслеген раслыйм.

«Шәхси мәгълүматлар турында» 2006 ел, 27 июль, ФЗ-152 нче Федераль закон нигезендә, мине юллама белән тәэмин итү максатларыннан чыгып, бу гаризада

күрсәтелгән шәхси мәгълүматларымны мәгълүмат алмашу системасында эшкәртүгә, шул исәптән җыюга, тәгаенләүгә, файдалануга, тапшыруга ризалыгымны бирәм.

Мәгълүмат (хәбәрнамә), шул исәптән шифаханә-курорт дәвалавына юллама бирү (бирүдән баш тарту) турында) алуга ________________________________ риза.
(язмача, телефон, смс-хәбәр, электрон почта аша)

Яшәү адресым, мобиль телефон номерым яисә электрон почта адресым үзгәрсә, бу турыда өстәмә рәвештә хәбәр итәчәкмен.

Дата                                                    Имза

________________________________________